**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Коштаулы авыл җирлеге Башкарма комитеты**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 1 февраль №3

**Коштаулы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карарына таянып, җирләү һәм җирләү эше турында», Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 февраленнән, әлеге карарның 1 нче кушымтасы һәм 2 нче кушымтасы нигезендә, Коштаулы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6424,98 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен үзем тикшереп торам.

**Коштаулы авыл**
**җирлеге Башлыгы Х.Ф.Сабиров**

1 нче кушымта

Коштаулы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән ирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *( сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| Мәетне төрү | 2024,09 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 810,80 |
| 4. Мәетне (җәсәдләрен) зиратка илтү | 909,48 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2680,61 |
| Барлыгы | 6424,98 |

2 нче кушымта

Коштаулы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән ирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2506,64 |
| 3. Мәетне (җәсәдләрен) зиратка илтү | 964,24 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2954,10 |
| Барлыгы | 6424,98 |